КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 62

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 952 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 29 апрель, 359 нчы; 2019 ел, 6 сентябрь, 797 нче, 2019 ел, 25 октябрь, 957 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

сиксән өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, дәүләт граждан хезмәте

вазыйфалары булмаган хезмәткәрләрнең, шулай ук дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппараты хезмәткәрләреннән тыш, һөнәри белем (квалификация күтәрү, һөнәри әзерлек) буенча һөнәри үсеш чараларын оештыра;

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, җирле үзидарә органнарында вазыйфалар биләүче, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган хезмәткәрләрнең, шулай ук муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең һөнәри үсеше, шул исәптән өстәмә һөнәри белем (квалификация күтәрү, һөнәри әзерлек) буенча чараларны оештыра;

Татарстан Республикасында формалаштырыла торган кадрлар резервларына кертелгән затларны әзерләүне (укытуны, стажировкаларын) оештыра;

дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерү кысаларында семинарлар, киңәшмәләр, башка чаралар, шул исәптән Россия һәм чит ил әйдәүче белгечләрен җәлеп итеп оештыра;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин